| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от “18” 04. 2019 № 162

Казан ш.

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларны башкару, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, конкурстан башка гына билгеләнеп куела торган аерым вазыйфалары исемлеген раслау турында

“Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсенең 3 бүлекчәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларны башкару, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, конкурстан башка гына билгеләнеп куела торган аерым вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының түбәндәге боерыклары үз көчен югалткан дип танырга:

“Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларны башкару, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган һәм конкурстан башка гына билгеләнергә мөмкин булган аерым вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертү турында” 2012 елның 5 июлендәге 117 номерлы боерыгы;

“Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларны башкару, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган һәм конкурстан башка гына билгеләнергә мөмкин булган аерым вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында” 2012 елның 12 сентябрендәге 154 номерлы боерыгы;

“Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларны башкару, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, конкурстан башка гына билгеләнеп куела торган аерым вазыйфалары исемлеген раслау турында” 2015 елның 8 августындагы 291 номерлы боерыгы;

“2015 елның 4 августындагы № 291 номерлы Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларны башкару, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, конкурстан башка гына билгеләнеп куела торган аерым вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертү турында” 2015 елның 8 августындагы 291 номерлы боерыгы;

3. Әлеге боерыкның үтәлүен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының
2019 елның 18 апрелендәге
162 номерлы боерыгы белән расландь

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларны башкару, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, конкурстан башка гына билгеләнеп куела торган вазыйфалары исемлеге

1. Эшләр белән идарә итүче;
2. транспорт идарәсе башлыгы;
3. Стратегик үстерү идарәсе башлыгы;
4. Финанс бүлеге башлыгы;
5. Режим, мобилизацион әзерлек, гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлеге башлыгы;
6. Автомобиль юллар бүлеге әйдәп баручы консультанты;
7. Режим, мобилизацион әзерлек, гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлеге әйдәп баручы белгече;
8. Финанс бүлеге әйдәп баручы белгече.